**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН СУЫК-СУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

« 03 » апрель 2024 ел Түбән Суык-Су № 9

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге составына керүче Яңа Мусабай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 26 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 26 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Яңа Мусабай авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Яңа Мусабай авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Түбән Суык-Су авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Түбән Суык-Су авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Советының 2019 елның 27 июнендәге 5/2 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге составына керүче Яңа Мусабай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 26 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 26 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Яңа Мусабай авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апреленә мартына 16.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге составына керүче Яңа Мусабай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 26 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны

ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, махсус техника хезмәте күрсәтү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырткычларын урнаштыру, монтажлау, электр җиһазлары һәм комплектлау элементларын сатып алу)»

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 26 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Яңа Мусабай авылында гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау»

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Түбән Суык-Су авыл җирлеге, Яңа Мусабай авылы, Үзәк ур., 13А йорт (парк территориясе).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башлык урынбасары Д.З.Фазуллин